## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ ТУРЫНДА

Лөгатьлектәге сүзләр гамәлдәге алфавит тәртибендә бирелде. Бериҗекле сүзләрдән тыш, басым һәр очракта күрсәтелде.

*Ихтирам итү, кабул итү, иялек килеше* кебек сүзтезмәләр һәм тезмә конструкцияләр, *кеше-фәлән, әйбер-кара, кунак-мазар* кебек икенче компоненты теләсә кайсы исемгә тагылып килә алган сүзләр сүзлеккә алынмады.

Сүзнең язылышы белән укылышында аерма булмаса, бернинди тамгаларсыз һәм җәяләрсез бирелә:

> **күк**,
> күгé, күккә́, күктә́н

Язылыш белән укылыш арасында аерма булса, сүзнең дөрес укылырга тиешле иҗеге (яки сүз тулысы белән) квадрат җәяләр эчендә күрсәтелә:

> **авылда́ш** [ў̆ыл],
> авылдашы, авылдашка, авылдаштáн
> **бөрке́т** [бөркө́т],
> бөркетé, бөркеткә́, бөркеттә́н
> **каньо́н** [кан$^{\text{ь}}$йóн],
> каньоны, каньонгá, каньоннáн, каньоннар

Исем фигыльләрдә, шулай ук [и] авазына тәмамланган сүзләрдә [$^{\text{ў}}$], [$^{\text{ү}}$] һәм [$^{\text{й}}$] аваз төсмерләре күрсәтелә. Шул ук вакытта соңгы иҗек, уртадан өзелмичә, тулысы белән бирелә. Сүз формаларында фонетик үзгәреш күзәтелсә, шул үзгәреш иҗеге/иҗекләре квадрат җәяләр эчендә чагылдырыла:

> **кенәри́** [и$^{\text{й}}$],
> кенәриé [рийё́], кенәригә́, кенәридә́н
> **мавыгу́** [ў̆ыгу́$^{\text{ў}}$],
> мавыгуы́ [гуў̆ы́], мавыгугá, мавыгудáн

Әгәр дә омоним сүзләрнең әйтелешендә аерма юк икән, алар омонимнар буларак күрсәтелми, бер сүз булып бирелә,

янына бернинди аерым билге куелмый. Әгәр дә омонимнар төрлечә әйтелсә, һәрберсе аерым мәкалә итеп бирелә:

**йөз**,
йөзе [йөзө́], йөзгә́, йөздә́н

**каза́к** [қаᵒза́қ],
казагы́ [ғы́], казакка́ [ққа́], казакта́н

**каза́к** [каза́к],
казагы́ [гы́], казакка́ [кка́], казакта́н

Исемнәр парадигмасыннан III зат тартым кушымчасы кулланылган форма, юнәлеш һәм чыгыш килешләре формасы, [н], [ң], [м] сонор авазларына тәмамланган исемнәрнең күплек саны формасы күрсәтелә (әгәр дә сүз -лл га бетсә, күплек саны шулай ук бирелә):

**кибе́т**,
кибете́, кибеткә́, кибеттә́н

**җан**,
җаны́, җанга́ [җаᵒңға́] *шулай ук* [җаᵒнға́], җанна́н, җанна́р

**ато́лл** [ато́л],
атоллы́ [атолы́], атоллга́, атоллда́н, атолла́р

Баш сүз булганда, фигыльләр инфинитив формада бирелә. Фигыльләр парадигмасыннан боерык форма, хикәя фигыльнең хәзерге заман һәм киләчәк заман формаларының III зат берлек саны күрсәтелә:

**искерергә́**,
иске́р, искерә́, искерәчә́к

Асыл сыйфатлар белән рәвешләрнең чагыштыру дәрәҗәләре бирелә, тартыкка тәмамланган сыйфатлар һәм рәвешләрдән соң *-рак* алдыннан *-ы-* яки *-ě-* аваз төсмере күрсәтелә:

**мактанчы́к**,
мактанчыграк [чы́ғʸра́қ]

**ти́з**,
тизрә́к [тизᵉрә́қ]

Исем дә, сыйфат та булып йөргән сүзләр ике төрле бирелә: әгәр дә сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе булса, исемнең дә, сыйфатның да үз формалары күрсәтелә; әгәр дә сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе булмаса, сыйфат формасы бирелми:

**искé-москы** [искё̆мŏсқŏ],
искé-москысы, искé-москыга, искé-москыдан

**мактанчы́к**,
мактанчыгы́, мактанчыкка́, мактанчыкта́н

**мактанчы́к**,
мактанчыграк [чы̆ғ<sup>ы</sup>ра́қ]

Кагыйдә буларак, *е, ё, ю, я* хәрефләре һәр очракта да ачылып бирелә:

**амёба** [амьóба]...

**әүлия́** [әү̆лийа́]...

**кыюлы́к** [йу]...

**юкә́** [йүкә́]...

Язуда аерым билгеләр белән белдерелмәгән кече тел *к, г, х*, шулай ук өрелмәле ирен-ирен авазлары [қ], [ғ], [ҳ], [ў] яки [ү̆] билгеләре белән бирелә:

**сихе́р** [ҳ],
сихере́, сихергә́, сихердә́н

Алынмаларда очрый торган *а* хәрефе [а°] булып, *о* хәрефе [ŏ] булып, *ы* хәрефе [ы̆] булып, *э/е* хәрефе [ё̆] булып яңгырамаганда, шулай ук татар теленә хас булмаган алынма [тч], [в], [х], [щ] авазлары һәм [ʼ] – һәмзә һәрвакыт күрсәтеләләр:

**монасты́рь** [манасты̆йрь],
монастыре́(нá), монастырьгá, монастырьдáн

**тәэми́н** [тәʼми́н],
тәэмине́, тәэмингә́, тәэминнә́н, тәэминнә́р

**маэма́й** [ма°ʼма́й],
маэмае́ [йы̆], маэмайгá, маэмайдáн

Палаталь авазлар юл өстенә куелган ь, веляр авазлар ъ белән билгеләнә:

**каньон** [каньйóн],
каньоны́, каньонгá, каньоннáн, каньоннáр

**гра́фик** [гра́фикъ],
гра́фигы [гы̆], гра́фикка, гра́фиктан

Нечкәлек билгесенә тәмамланган алынма исемнәрнең, йомшаклыгын яки катылыгын күрсәтү өчен, тартымлы

формасыннан соң җәяләр эчендә юнәлеш килеше кушымчасы бирелә:

**календáрь** [калиндáр$^{ь}$],
календарé(нá), календарьгá, календарьдáн

Ауслауттагы *з* [з$^{с}$] итеп бирелә:

**көндéз** [көндө́з$^{с}$]

Ассимиляция күзәтелгән сүзләрнең баштан өстенлекле варианты, аннары сүзлекне төзүчеләр фикеренчә әдәби норма кысаларыннан чыкмаган дип саналган формасы күрсәтелә:

**комлы́к** [қŏмлŏ́қ] *һәм* [қŏмнŏ́қ],
комлыгы́, комлыккá, комлыктáн